ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШИШИНЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
24.06.2025

КАРАР
№35

«Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплау урыны (урыннары) булдыру һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 28 мартындагы 5 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яктырту җайланмалары, электр лампалары, аларны тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру,күчереп йөртү һәм урнаштыру гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булган җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү кагыйдәләрен раслау турында»гы 2020 елның 28 декабрендәге 2314 номерлы карары таләпләрен үтәү йөзеннән, Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитетының 28.03.2023 №5 карарына Балтач районы прокуратурасының 16.06.2025 02-08-01-2025/Прпд200-25-20920011 протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә файдаланылган терекөмешле лампаларны туплау урынын (урыннарын) булдыру һәм кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 2023 елның 28 мартындагы 5 номерлы Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 5 пунктта «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарында мәгълүмат стендларында» сүзләрен «әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында» сүзләренә алмаштырырга.

3. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

2. Әлеге карарны интернетта - «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы

Р.Х.Салихжанов